| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

04.04.2024 ел Баулы шәһәре №50

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 136 номерлы карары белән расланган, спорт разряды бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе спорт Министрлыгының «Бердәм Бөтенроссия спорт классификациясе турындагы нигезләмәне раслау турында» 2022 елның 19 декабрендәге 1255 номерлы боерыгы буенча, Баулы шәһәр прокуратурасының 2024 елның 5 мартындагы Прдп-14-24 номерлы протестын карап чыкканнан соң, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 136 номерлы карары белән расланган, спорт разряды бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

2 бүлектә «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартлары»:

2.4. пунктының 2.4.1. пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Спорт разряды бирү өчен документларны карау вакыты теркәлгән көннән алып 16 эш көне тәшкил итә. Спорт разрядын бирү яки бирүдән баш тарту турында карар кабул итү спорт разрядын бирү өчен документларны карау тәмамланганнан соң 3 эш көне эчендә башкарыла.»;

2.5. пунктның 2.5.1. подпуктын:

унберенче абзацны түбәндәге эчтәлектәге җөмлә белән тулыландырырга:

«Документларны электрон формада биргәндә, документтагы шәхесне раслаучы мәгълүматлар, тиешле кырларга интерактив портал формасында кертеләләр һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасын кулланып, сорауны юнәлтү юлы белән тикшереләчәкләр»;

ундүртенче абзацны түбәндәге эчтәлектәге җөмлә белән тулыландырырга:

«Документларны электрон формада биргәндә, туу турындагы таныклыктагы мәгълүматлар тиешле кырларга интерактив портал формасында кертеләләр һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасын кулланып, сорауны юнәлтү юлы белән тикшереләчәкләр. Әгәр туу турында таныклык чит телдә бирелгән булса, аның төп нөсхәсен һәм нотариаль рәвештә расланган тәрҗемәсен тәкъдим итәргә кирәк. Документларны электрон формада тапшырганда нотариусның электрон имзасы белән имзаланган нотариаль расланган тәрҗемә бирелә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров